**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 2 май № 256

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 318 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 318 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2006 ел, 18 апрель, 192 нче; 2006 ел, 21 апрель, 199 нчы; 2007 ел, 7 ноябрь, 621 нче; 2008 ел, 28 март, 196 нчы; 2008 ел, 2 октябрь, 720 нче; 2010 ел, 28 октябрь, 864 нче; 2010 ел, 10 декабрь, 1042 нче; 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2011 ел, 17 март, 197 нче; 2011 ел, 13 сентябрь, 762 нче; 2012 ел, 16 март, 221 нче; 2012 ел, 24 март, 237 нче; 2012 ел, 6 август, 668 нче; 2012 ел, 26 декабрь, 1153 нче; 2013 ел, 31 гыйнвар, 54 нче; 2013 ел, 14 март, 161 нче; 2013 ел, 14 май, 323 нче; 2014 ел, 12 апрель, 238 нче; 2014 ел, 8 июль, 471 нче; 2014 ел, 8 август, 575 нче; 2015 ел, 10 август, 578 нче; 2015 ел, 24 декабрь, 969 нчы; 2016 ел, 22 гыйнвар, 32 нче; 2016 ел, 15 июнь, 405 нче; 2016 ел, 3 октябрь, 702 нче; 2016 ел, 14 декабрь, 933 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.3 пунктка «Татарстан Республикасы Мәгълүмат технологияләре үзәге» сүзләреннән соң «Иннополис шәһәре» автоном коммерциячел булмаган оешмасы.» сүзләрен өстәргә;

3.3 пунктта:

3.3.3 пунктчага түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Татарстан Республикасы Югары Ослан һәм Лаеш муниципаль районнары территорияләрендә төзелгән «Иннополис» техник-гамәлгә кертү тибындагы махсус икътисадый зона резидентлары реестрын алып бара (алга таба – махсус икътисадый зона);

махсус икътисадый зона резидентлары таләпләре яки мәнфәгатьле затлар соравы буенча махсус икътисадый зона резидентлары реестрыннан өземтәләр бирә;

махсус икътисадый зона резидентының сәнәгать-җитештерү, техник-гамәлгә кертү, туристик-рекреацион эшчәнлекне яки портлы махсус икътисадый зонада эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында килешүләрне үтәвен тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыра;

«Россия Федерациясендә махсус икътисадый зоналар турында» 2005 елның 22 июлендәге 116-ФЗ номерлы Федераль закон белән расланган тәртиптә техник-гамәлгә кертү яки сәнәгать-җитештерү эшчәнлеген гамәлгә ашыру турында килешү төзи;

махсус икътисадый зона чикләрендә территорияне планлаштыру буенча документлар әзерләү һәм, әгәр Россия Федерациясе законнарында бүтәне билгеләнмәсә, күздә тотылган федераль бюджет, Татарстан Республикасы бюджеты, җирле бюджет акчасы исәбеннән әлеге зонаның  инженер, транспорт, социаль, инновацион һәм бүтән инфраструктураларын төзү буенча дәүләт заказчысы функцияләрен башкара;

Татарстан Республикасының мәгълүматлаштыру һәм элемтә тармаклары предприятиеләренә тармак аудиты һәм эшчәнлекләренә функциональ анализ үткәрүне оештыра»;

4 бүлектә:

4.1 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Татарстан Республикасының мәгълүматлаштыру һәм элемтә тармагында проблемаларын хәл итүгә шартнамә нигезендә фәнни оешмаларны, галимнәрне һәм белгечләрне, шул исәптән чит илдән, җәлеп итә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин